**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге Советы**
**КАРАР**

№ 8/1 09.04.2015 ел

**Аксубай муниципаль районы җирле әһәмияттәге Аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елдагы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияткә ия киләсе мәсьәләне хәл итү буенча вәкаләтләрне тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

- җирлек чикләрендә Халыкны электр, газ һәм су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру;

-җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларда юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары) булдыру һәм аларның эшчәнлеген тәэмин итү, җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контроль башкарудан тыш, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә юл эшчәнлеген башкару өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру;

- җирлектә яшәүчеләрнең күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халык күпләп ял итә торган урыннарны, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буйларына ирекле үтеп керүен тәэмин итүне оештыру.

2.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Советы тарафыннан әлеге карарның 1 пунктында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге башкарма комитетына күрсәтелгән тәкъдимнәр кабул ителгән очракта: әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә;

әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге Советының 2015 елга һәм 2016, 2017 еллар план чорына Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Савруш авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карар проектын бюджет законнары нигезендә эшләргә һәм карап тикшерүгә тапшырырга.

3.Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://Aksubayevo.tatarstan.ru

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Савруш авыл җирлеге башлыгы,

Совет рәисе: А.Г.Кузьмин.